**Татарстан Республикасы**
**Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге**
**Советы Карары**

2018 елның 31 маендагы 14№

Югары Колчура авыл җирлегенең 2016 елның 13 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 197 елның 30 мартындагы 197№ карары нигезендә Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 1.1 Пункт 1 абзац «Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә муниципаль хезмәттән азат ителгәндә муниципаль хезмәт стажы булганда,муниципаль вазыйфаны биләп торучы затка һәм муниципаль хезмәткәргә эштән азат ителгән көнгә муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча аның айлык акчалата кереме биш тапкыр бирелә торган күләмдә түләнә, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләүозынлыгы исәпләнелә:

- 2018 елда 16 ел,
- 2019 елда 1 ел да 6 ай,
- 2020 елда 17 ел,
- 2021 елда 17 ел да 6 ай,
- 2022 елда 18 ел,
- 2023 елда 18 ел да 6 ай,
- 2024 елда 19 ел,
- 2025 елда 19 ел да 6 ай,
- 2026 һәм аннан соңгы елларда 20 ел

муниципаль хезмәтнең һәр киләсе тулы елы өчен-өстәмә рәвештә 0,5әр акчалата керем, әмма муниципаль хезмәткәрнең акчалата эчтәлегенең ун күләменнән артмаган (алга таба - пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә бүләкләү).»

2. «Әлки муниципаль районының Югары Колчура авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә» 29 статьясындагы 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Бер мәртәбә бүләкләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата түләү составына вазыйфаи оклад, сыйныф чины өчен оклад һәм муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү керә.»

3. 29 статьяның 1.4 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә, Әлки муниципаль районы Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы бюджетыннан акча бүлеп бирү турында карар кабул ителгәннән соң бер айдан да соңга калмыйча Әлки муниципаль районы бюджетыннан пенсиягә чыгу сәбәпле муниципаль вазыйфаны һәм муниципаль хезмәткәрне биләүче затка бер мәртәбә бүләкләүгә акча алу турында карар кабул ителә».

4. Әлеге карар имзалау мизгеленнән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы
Югары Колчура авыл җирлеге башлыгы: Е.В.Краснова